КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 июнь г.Казань № 485

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1256 нчы карары белән расланган 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1256 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 08 апрель, 278 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның I бүлегендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа медицина ярдәмен күрсәтү тәртипләрен, медицина ярдәме стандартларын һәм клиник тәкъдимнамәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы халкының җенесе-яше составы үзенчәлекләрен, медицина статистикасына нигезләнгән Татарстан Республикасы халкының авыру дәрәҗәсе һәм структурасын исәпкә алып формалаштырылган.»;

Программаның II бүлегендәге егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданин бер елга кимендә бер тапкыр түләүсез профилактик медицина тикшерүенә хокуклы, шул исәптән диспансерлаштыру кысаларында.»;

Программаның III бүлегендәге 2 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«профилактик чараларга, шул исәптән гражданнарга һәм аларның Программаның II бүлегендә күрсәтелгән аерым категорияләренә профилактик медицина тикшерүләрен дә кертеп, шул исәптән диспансерлаштыру чикләрендә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган тәртипләргә туры китереп диспансерлаштыру;»;

IV бүлектә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмаларын күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән финанслана торган медицина ярдәме, медицина хезмәтләре»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмаларын күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә финанс белән тәэмин ителә:

мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән авыруларда медицина ярдәме өлешендә беренчел медик-санитар һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү (кеше иммунодефициты вирусы белән бәйле булган авырулар, алынган иммунодефицит синдромы, җенси юл белән күчә торган авырулар, туберкулез, психик бозылулар һәм үз-үзеңне тотуда бозылулар, шул исәптән психоактив матдәләр куллануга бәйле авырулар);

һава суднолары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган санитар-авиация эвакуациясе вакытында авиация эшләре;

амбулатор, шул исәптән өйдә, күчмә патронаж бригадалары тарафыннан күрсәтелә торган медицина ярдәмен дә кертеп, көндезге стационарда һәм стационар, шул исәптән паллиатив медицина ярдәмен һәм шәфкать туташлары карау койкаларын да кертеп, күрсәтелә торган паллиатив медицина ярдәме;

сәламәтлек саклауның дәүләт һәм муниципаль системаларының паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында пациентка һәм пациентның гаилә әгъзаларына психологик ярдәм күрсәтү, шулай ук паллиатив медицина ярдәме алучы пациентка һәм пациентның гаилә әгъзаларына, яки аның вафатыннан соң пациентның гаилә әгъзалары медицина оешмасына мөрәҗәгать иткән очракта табиб-психотерапевтлар тарафыннан медицина ярдәме күрсәтү;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1506 нчы карары белән расланган 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына кушымтаның II бүлеге белән билгеләнгән югары технологияле медицина ярдәме төрләре исемлеге буенча, Программага 1 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларында күрсәтелә торган югары технологияле медицина ярдәме. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына күрсәтелә торган югары технологияле медицина ярдәменә планлы йөкләмә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана;

алынган иммунодефицит һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш үзәкләрендә, бала йортларында, шул исәптән махсуслаштырылган, гаилә планлаштыру һәм репродукция үзәкләрендә (бүлекчәләрендә), «Казан шәһәренең 12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ачык акционерлык җәмгыятенең Һөнәри патологиянең республика үзәгендә, Казан шәһәренең «7 нче шәһәр балалар сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Психоневрология авырулары булган инвалид балалар өчен торгызу дәвалау үзәгендә, Казан шәһәренең, «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Лаборатория диагностикасы үзәгендә медицина ярдәме һәм медицина хезмәтләре күрсәтү;

балалар шифаханәләре шартларында балаларны савыктыру буенча чаралар;

наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз куллануын иртә (үз вакытында) ачыклау максатларында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында, шулай ук югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларны профилактик медицина тикшерүләре (экспресс-тест бәясеннән тыш);

баланы уллыкка (кызлыкка) алырга, опекага (попечительлеккә) алырга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны асрамага алган яисә патронат гаиләгә алырга теләгән иминләштерелгән затларны мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кермәгән авырулар һәм хәлләр өлешендә медицина тикшерүе үткәрү максатларында табиблар карау һәм диагностик тикшеренүләр үткәрү;

мәҗбүри медицина иминияте системасында иминләштерелмәгән һәм идентификацияләнмәгән затларга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керә торган авырулар һәм халәтләрдә медицина оешмасыннан читтә күрсәтелгән ашыгыч һәм кичектергесез формада (ашыгыч медицина ярдәме),

стационар шартларда ашыгыч рәвештә, амбулатор шартларда кичектергесез формада (травматология пунктларында, кабул итү (кабул итү-диагностика) бүлекләрендә) күрсәтелгән медицина ярдәме;

ашыгыч медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре тарафыннан медицина оешмасыннан тыш мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затларга, шулай ук туберкулез, психик бозылулар һәм үз-үзеңне тотуда бозылулар, шул исәптән психоактив матдәләр куллануга бәйле авыруларда мәҗбүри медицина иминияте системасында иминләштерелмәгән һәм идентификацияләнмәгән затларга ашыгыч яки кичектергесез формада күрсәтелгән медицина ярдәме;

ашыгыч медицина ярдәме күрсәткәндә хәрби хезмәткәрләргә, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарга, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләренә, җинаять-үтәтү системасы, таможня органнары хезмәткәрләренә һәм Федераль фельдъегер хезмәтенең җитәкче составы затларына медицина ярдәме күрсәтү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибе нигезендә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләрен күрсәтү;

йөкле хатын-кызларда бала үсешенең бозылуына пренаталь (бала тудырганчы) диагностика үткәрүгә, медицина-генетика үзәкләре (консультацияләре) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган тикшеренүләр һәм консультацияләр өлешендә нәселдән һәм тумыштан килгән биш авыруга, шулай ук медицина оешмаларының тиешле структур бүлекчәләрендә медик-генетик тикшеренүләр һәм консультацияләр өлешендә неонаталь скрининг үткәрүгә юнәлдерелгән чаралар;

субъектларның дәүләт хакимияте башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларында трансплантация (күчереп утырту) максатларында кеше органнары һәм тукымалары донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеге;

субъектларның дәүләт хакимияте башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларында берәмлеге өчен 100 мең сумнан артык бәягә төп чаралар (җиһазлар, җитештерү һәм хуҗалык инвентаре) сатып алу чыгымнары.

Социаль хезмәтләр күрсәтүне һәм пациентка, шул исәптән күчмә патронаж бригадалары эшчәнлеге кысаларында социаль яклау (ярдәм) чараларын күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

Программаның VI бүлегендә:

1.1 пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«паллиатив медицина ярдәме, шул исәптән паллиатив беренчел медицина ярдәме, табибка кадәр һәм табиблык һәм паллиатив махсуслаштырылган медицина ярдәмен дә кертеп.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Паллиатив медицина ярдәме амбулатор шартларда, шул исәптән өйдә, көндезге стационар һәм стационар шартларда мондый ярдәм күрсәтү буенча укулар узган медицина хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез күрсәтелә.

Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары пациент гаиләсенең туганнары һәм башка гаилә әгъзалары яисә пациентның законлы вәкиле, пациентны карауны гамәлгә ашыручы затлар, ихтыярый ярдәмчеләр (волонтерлар), шулай ук социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, дини оешмалар, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар белән, шул исәптән мондый пациентка социаль хезмәтләр күрсәтү, Россия Федерациясе законнары нигезендә социаль яклау (ярдәм) чараларын, психологик ярдәм һәм рухи ярдәм чаралары гамәлгә ашыру максатларында үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыралар.

Пациент беренчел медик-санитар ярдәм алу өчен беркетелгән медицина оешмасы аңа, фельдшерлык пунктларының, фельдшерлык-акушерлык пунктларының, табиб амбулаторияләренең һәм беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының бүтән бүлекчәләренең медицина хезмәткәрләрен кертеп, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының күчмә патронаж бригадалары белән һәм паллиатив махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары белән үзара хезмәттәшлектә медицина хезмәткәрләре тарафыннан паллиатив беренчел медицина ярдәме күрсәтүне оештыра.

Махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары, шул исәптән амбулатор шартларда паллиатив беренчел медицина ярдәменә мохтаҗ пациент ачыкланган очракта паллиатив ярдәәмне дә, шул исәптән өйдә дә, күрсәтелгән пациентның махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасыннан чыгаруны гамәлгә ашыруга өч көн кала, шул исәптән паллиатив, стационар шартларда һәм көндезге стационар шартларда, мондый пациент беренчел медик-санитар ярдәм алу өчен беркетелгән медицина оешмасына хәбәр итәләр, яки аның тору урынына якын урнашкан беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмасына хәбәр итәләр.

Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мондый медицина оешмалары һәм аларның бүлекчәләре, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган исемлек буенча, кирәкле дару препаратлары, шул исәптән наркотик дару препаратлары һәм психотроп дару препаратлары белән өйләрендә куллану өчен, кеше организмының органнары һәм системалары функцияләрен саклау өчен билгеләнгән медицина эшләнмәләре белән тәэмин ителә.

Паллиатив медицина ярдәмен үстерү чаралары үз эченә күрсәтелгән чараларны, шулай ук аларның нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләрен алган Татарстан Республикасының тиешле дәүләт программалары кысаларында гамәлгә ашырыла.

Гражданнарны өйдә кеше организмының органнары һәм системалары функцияләренә ярдәм итү өчен каралган медицина эшләнмәләре, шулай ук наркотик дару препаратлары һәм психотроп дару препаратлары белән тәэмин итү Татарстан

Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Тәртип нигезендә өйдә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү чикләрендә тәэмин ителә.»;

4 бүлекчәгә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Профилактик чаралар үткәрү чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гражданнар тарафыннан профилактик медицина тикшерүләре, диспансеризация узуны оештыруны тәэмин итә, шул исәптән кичке сәгатьләрдә һәм шимбә көннәрендә, шулай ук гражданнарга медицина тикшеренүләренә дистанцион язылу мөмкинлеге бирә.

Профилактика чаралары шул исәптән халык үлеменең төп сәбәпләрен формалаштыручы кан әйләнеше системасы авыруларын һәм онкология авыруларын ачыклау өчен оештырыла.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтларында гражданнар профилактик медицина тикшерүләрен, шул исәптән диспансеризацияне дә узарга мөмкин булган медицина оешмалары турында мәгълүмат урнаштыра.

Кирәк булган очракта профилактик медицина тикшерүләрен узу чикләрендә медицина тикшеренүләрен үткәрү, диспансерлаштыру өчен махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләре җәлеп ителергә мөмкин.

Профилактик медицина тикшерүләрен уздыру буенча медицина хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү, шул исәптән диспансерлаштыру кысаларында, эш вакытының дәвамлылыгын исәпкә алып, Россия Федерациясенең хезмәт законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

12.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Амбулатор шартларда медицина хезмәткәрләре тарафыннан пациентларны кабул итүне оештыру (алдан язылу, авыруларны амбулатор кабул итүгә үз-үзеңне теркәү) һәм өйгә табиб чакырту тәртибе (табибның өйгә чакырулары, регистратураның уңайлы эш режимы теркәлгән телефоннарны күрсәтү) һәм өйдә медицина ярдәме күрсәтү медицина оешмасы эшенең эчке кагыйдәләре белән регламентлана. Планлы медицина ярдәмен күрсәтүне тәртипкә салу максатларында пациентларны шул исәптән электрон рәвештә яздыралар.

Медицина ярдәме күрсәткәндә түбәндәгеләр күздә тотыла:

участок табиб-терапевты, участок табиб-педиатры, гомуми практика табибы (гаилә табибы) кабул итүне көтү пациентның медицина оешмасына мөрәҗәгать иткән вакыттаналып 24 сәгатьтән артмаска тиеш;

планлы формада беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм күрсәткәндә табиб-белгечләрнең консультацияләрен үткәрү срогы пациент медицина оешмасына мөрәҗәгать иткән көннән алып 14 календарь көннән артмаска тиеш;

диагностика инструменталь (рентгенографик тикшеренүләр, маммографияне, функциональ диагностика, ультратавыш тикшеренүләрен кертеп) һәм беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә лаборатор тикшеренүләр үткәрү вакыты, шулай ук онкология авырулары диагнозын билгеләү сроклары тикшеренүләр билгеләнгән көннән алып 14 календарь көннән артмаска тиеш;

онкология авыруы ачыкланган пациент өчен табиб-онкологның диспансер күзәтүен билгеләү срогы онкология авырулары диагнозы куелганнан соң өч эш көненнән дә артмаска тиеш;

планлы формада беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә компьютер томографиясен (бер фотонлы эмиссион компьютер томографиясен дә кертеп), магнит-резонанс томографиясен һәм ангиографиясен үткәрү вакыты 30 календарь көннән артмаска тиеш, ә онкология авырулары булган пациентлар өчен – билгеләнгән көннән 14 календарь көн.

Амбулатор авыруның медицина картасында консультация һәм (яки) тикшеренүләр билгеләү һәм үткәрү даталары күрсәтелә.

Табиб-белгечләрнең консультацияләре пациент беркетелгән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасының дәвалаучы табибы җибәрүе буенча гамәлгә ашырыла.»;

14.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.1. Көндезге стационар шартларында һәм кичектергесез формада беренчел медик-санитар ярдәм программасы кысаларында махсуслаштырылган медицина ярдәме, шул исәптән югары технологияле, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме, стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә, көндезге стационар шартларында һәм өйдә булганда гражданнарны медицина эшләнмәләре һәм медицина әйберләре белән тәэмин итү гамәлгә ашырыла, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлеге һәм кеше организмына имплануучы медицина эшләнмәләре исемлеге, шулай ук Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган исемлек нигезендә паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өйдә куллану өчен кеше организмының органнары һәм системалары функцияләрен саклау өчен билгеләнгән медицина эшләнмәләре.

Медицина оешмасыннан пациентка (аның законлы вәкиленә) кеше организмының органнары һәм системалары функцияләрен саклау өчен билгеләнгән медицина әйберләрен паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өйдә файдалану өчен тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Гражданнарны дару препаратлары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр, дәвалау ризыгы, шул исәптән дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итү билгеләнгән тәртиптә расланган медицина ярдәме стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Медицина ярдәменең тиешле стандартына һәм (яки) тереклек өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кермәгән дару препаратларын, медицина эшләнмәләрен һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктларын билгеләү һәм куллану табиб комиссиясе карары буенча медицина күрсәткечләре (шәхси кабул итә алмау, тормыш күрсәткечләре буенча) булган очракта рөхсәт ителә. Табиб комиссиясе карары пациентның медицина документларында һәм табиб комиссиясе журналында теркәлә.»;

Программаның VII бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «VII. Медицина ярдәме күләме нормативлары

Программа буенча тулаем алганда кърсщтъ төрләре, шартлары һәм формалары буенча медицина ярдәме күләме нормативлары бер елга мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы буенча бер иминләштерелгән кешегә исәпләгәндә күләм берәмлекләрендә билгеләнә. Медицина ярдәме күләме

нормативлары Программада каралган финанс тәэмин итүнең җан башына туры килә торган нормативлары күләмен планлаштыру һәм финанс-икътисадый нигезләү максатларында файдаланыла һәм түбәедәгеләр өчен төзелә:

медицина оешмаларыннан читтә ашыгыч медицина ярдәме, һава суднолары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган санитар-авиация эвакуациясен кертеп, Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән 2019 – 2021 елларга – бер кешегә 0,018 чакыру, 2019 елга ММИ база программасы кысаларында –бер иминләштерелгән затка 0,3 чакыру, 2020 һәм 2021 елларга бер иминләштерелгән затка 0,29 чакыру;

профилактик һәм башка максатлар белән күрсәтелә торган амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтү (профилактик чараларга, шул исәптән сәламәтлек үзәкләренә бару, шулай ук урта медицина персоналына бару һәм авырулар белән бәйле рәвештә бер тапкыр бару, шул исәптән авыз куышлыгы, төкерек бизләре һәм теш казнасы авыруларыннан тыш, теш протезлаудан тыш),

2019 елга ММИ база программасы кысаларында – бер иминләштерелгән затка 2,88 карау, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 2,9 карау, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 2,92 карау, алардан профилактик медицина тикшерүләре уздыру өчен[1], шул исәптән диспансеризация кысаларында, онкология авыруларын ачыклауны да кертеп, 2019 елга – бер иминләштерелгән затка 0,79 карау, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,808 карау, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка – 0,826 карау, шул исәптән 2019 елга диспансеризация кысаларында бер иминләштерелгән затка – 0,16 комплекслы карау, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,174 комплекслы карау, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 0,189 комплекслы карау, Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән 2019 – 2021 елларга – бер кешегә 0,33 карау (шул исәптән өйдә дә паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне кертеп), шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

2019 елга медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 2,54 карау, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка – 2,56 карау, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 2,58 карау;

2019 елга бер иминләштерелгән затка медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – 0,34 карау, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка – 0,34 карау, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 0,34 карау;

2019-2021 елларга медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән:

медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,2 тапкыр карау;

медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,13 тапкыр бару;

бер иминләштерелгән затка авырулар белән бәйле рәвештә күрсәтелә торган амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүнең 2019 – 2021 елларга ММИ база программасы кысаларында 1,77 мөрәҗәгать (амбулатор шартларда чирне дәвалауның тәмамланган очрагы, шул исәптән медицина реабилитациясен уздыруга

[1] Авыр эшләрдә һәм зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләүче хезмәткәрләрне беренчел һәм периодик медицина тикшерүеннән тыш.

бәйле рәвештә, бер авыру уңаеннан кимендә 2), 2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер кешегә 0,136 мөрәҗәгать, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 1,67 мөрәҗәгать;

медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,1 мөрәҗәгать;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән:

медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,109 мөрәҗәгать;

медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,027 мөрәҗәгать;

мәҗбүри медицина иминиятенең 2019 елга база программасы кысаларында кичектергесез формада күрсәтелә торган амбулатор шартларда медицина ярдәмен күрсәтү өчен бер иминләштерелгән затка 0,56 карау, 2020 һәм 2021 елларга – бер иминләштерелгән затка 0,54 карау, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

2019 елга медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,5 кеше, 2020 һәм 2021 елларга – бер иминләштерелгән затка 0,48 тапкыр бару;

2019 елга медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,06 тапкыр бару, 2020 һәм 2021 елларга – бер иминләштерелгән затка 0,06 тапкыр бару;

2019-2021 елларга амбулатор шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән паллиатив медицина ярдәме патронаж бригадалары өйгә барып медицина ярдәме – бер кешегә 0,009 бару;

2019-2021 елларга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында көндезге стационарлар шартларында медицина ярдәме күрсәтүнең 0,062 очрагы, шул исәптән «онкология» юнәлеше буенча медицина ярдәме өчен 2019 елга – бер иминләштерелгән затка дәвалауның 0,00631 очрагы, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка дәвалауның 0,0065 очрагы, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка дәвалауның 0,00668 очрагы, бер иминләштерелгән затка дәвалауның 0,00668 очрагы, 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер кешегә дәваланунын 0,004 очрагы (көндезге стационар шартларында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү очракларын да кертеп), шул исәптән:

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,0014 дәвалау очрагы;

медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,0013 дәвалау очрагы;

медицина ярдәмен күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,0013 дәвалау очрагы;

стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүнең 2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер кешегә 0,0124 госпитализация очрагы, шул исәптән «онкология» юнәлеше буенча 2019 елга – бер иминләштерелгән затка 0,17556 госпитализация очрагы, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,7557 госпитализация очрагы, 2021 елга – бер кешегә 0,1761 госпитализация очрагы, шул исәптән "онкология" юнәлеше буенча медицина ярдәме өчен – бер кешегә иминләштерелгән зат, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка, 2021 елга – 0,01076 госпитализация очрагы, махсуслаштырылган медицина оешмаларында медицина реабилитациясе өчен, «медицина реабилитациясе» юнәлеше буенча медицина ярдәме күрсәтүнең һәм 2019 елга ММИ база программасы кысаларында медицина оешмаларының реабилитация бүлекләрендә – бер иминләштерелгән затка, 2020 һәм 2021 елларга госпитализация очрагы – 0,003 (шул исәптән, 0 – 17 яшьлек балалар реабилитациясе өчен 25 проценттан да ким булмаган күләмдә), шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе 2019 елга – бер иминләштерелгән затка 0,04457 госпитализация очрагы, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,04476 госпитализация очрагы, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 0,04476 госпитализация очрагы;

медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе 2019 елга – бер иминләштерелгән затка – 0,0804 госпитализация очрагы, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,08075 госпитализация очрагы, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 0,08075 госпитализация очрагы;

медицина ярдәмен күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе 2019 елга – бер иминләштерелгән затка – 0,05059 госпитализация очрагы, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,05006 госпитализация очрагы, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 0,05059 госпитализация очрагы;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәмен күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,0019 госпитализация очрагы;

медицина ярдәмен күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,0027 госпитализация очрагы;

медицина ярдәмен күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – бер кешегә 0,0078 госпитализация очрагы;

стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәтү (паллиатив медицина ярдәме койкаларын һәм шәфкать туташлары карау койкаларын да кертеп) 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер кешегә 0,02 койко-көн.

Фертиль яшьтәге хатын-кызлар санына бәйле гамәлдәге ихтыяҗны исәпкә алып экстракорпораль аталандыру вакытында медицина ярдәме нормативы 2019 елга ММИ база программасы кысаларында бер иминләштерелгән затка 0,000478 очрак, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,000492 очрак, 2021 елга – бер иминләштерелгән затка 0,000506 очрак.

Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелмәгән гражданнарга кинәт кискен авырулар вакытында, пациентның гомерен куркыныч астына куя торган мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керә хроник авыруларның кискенләшүе аркасында ашыгыч рәвештә күрсәтелә торган медицина ярдәме күләме амбулатор һәм стационар шартларда күрсәтелә торган медицина ярдәме күләме нормативларына кертелә һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән финанслана.»;

Программаның VIII бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2019 елга Программаны формалаштыру максатлары өчен медицина ярдәме күләме берәмлегенә финанс чыгымнары нормативлары:

һава суднолары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган санитар-авиация эвакуациясен кертеп, ашыгыч медицина ярдәмен чакыру (авиация эшләренә киткән чыгымнардан тыш), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 3 129,8 сум, ММИ чаралары исәбеннән – 2 314,0 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән амбулатор шартларда медицина оешмаларына (аларның структур бүлекчәләренә) медицина ярдәме күрсәткәндә (амбулатор шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәтү чыгымнарын да кертеп) профилактик һәм башка максатларга бер бару – 1 059,0 сум, мәҗбүри медицина иминияте акчасы исәбеннән профилактик медицина – 473,8 сум, мәҗбүри медицина иминияте акчалары исәбеннән профилактик медицина тикшерүләре уздыру өчен бер тапкыр бару– 1 021,5 сум, профилактик медицина тикшерүен һәм тикшерүләрнең өстәмә ысулларын, шул исәптән онкология авыруларын ачыклау максатларында, мәҗбүри медицина иминияте чаралары исәбенә диспансерлаштыруны уздыру өчен бер комплекслы карау-1 166,33 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән күчмә патронаж бригадалары тарафыннан өйләренә барып паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә бер бару (социаль хезмәткәрләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләр өчен түләү чыгымнарын һәм медицина әйберләрен өйдә бирү чыгымнарын исәпкә алмыйча) - 2 953,0 сум;

амбулатор шартларда медицина оешмалары (аларның структур бүлекчәләре) тарафыннан медицина ярдәме күрсәткәндә авыру буенча бер мөрәҗәгать Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 1 460,2 сум, мәҗбүри медицина иминияте чаралары исәбеннән-1 314,8 сум;

мәҗбүри медицина иминияте чаралары хисабына амбулатор шартларда ашыгыч рәвештә медицина ярдәме күрсәткәндә бер бару – 601,4 сум;

көндезге стационарлар шартларында дәвалауның бер очрагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 15 656,9 сум, мәҗбүри медицина иминияте чаралары исәбеннән – 19 700,7 сум, «онкология» юнәлеше буенча дәвалауның бер очрагы – 70 587,1 сум;

ММИ чаралары хисабына экстракорпораль аталандыруның бер очрагы – 113 916,5 сум;

стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) госпитализацияләүнең бер очрагы Татарстан

Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 97 698,6 сум, ММИ чаралары хисабына – 32 082,2 сум, ММИ профиле буенча «онкология» госпитализациясенең бер очрагы – 76 708,5 сум;

медицина реабилитациясе буенча «медицина реабилитациясе» юнәлеше буенча медицина ярдәме күрсәтүче махсуслаштырылган медицина оешмаларында һәм медицина оешмаларының реабилитация бүлекләрендә мәҗбүри медицина иминияте чаралары хисабына госпитализациянең бер очрагы – 34 658,4 сум;

стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) бер койко-көн (паллиатив медицина ярдәме койкаларын һәм шәфкать туташлары карау койкаларын да кертеп), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 3 431,8 сум.

2020 һәм 2021 елларга Программа нигезендә күрсәтелә торган медицина ярдәме күләме берәмлегенә финанс чыгымнары нормативлары:

ашыгыч медицина ярдәмен чакыру Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2020 елга 3 911,3 сум, 2021 елга 3 949,1 сум, ММИ чаралары исәбеннән – 2020 елга 2 408,3 сум, 2021 елга 2 513,8 сум тәшкил итә;

медицина оешмалары (аларның структур бүлекчәләре) тарафыннан амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәткәндә профилактик һәм башка максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән (паллиатив медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән өйдә, чыгымнарын да кертеп) – 2020 елга 1 080,7 сум, 2021 елга 1 080,7 сум, ММИ чаралары исәбеннән – 2020 елга 499,7 сум, 2021 елга 519 сум, ММИ чаралары исәбеннән профилактик медицина тикшерүләрен уздыру өчен бер кешегә 2020 елга 1 070,1 сум, 2021 елга 1 113,2 сум, профилактик медицина тикшерүләрен һәм тикшерүләрнең өстәмә ысулларын үз эченә алган диспансеризация үткәрү өчен бер комплекслы карауга, шул исәптән онкология авыруларын ачыклау максатларында, мәҗбүри медицина иминияте чаралары исәбеннән – 2020 елга 1 193,7 сум, 2021 елга 1 241,8 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән күчмә паллиатив медицина ярдәме патронаж бригадалары белән өйдә паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә бер бару (социаль хезмәткәрләр күрсәтә торган социаль хезмәтләр өчен түләү чыгымнарын һәм медицина әйберләрен өйдә бирү чыгымнарын исәпкә алмыйча) – 2020 елга 2 055,2 сум, 2021 елга 2 137,4 сум

медицина оешмалары (аларның структур бүлекчәләре) тарафыннан амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәткәндә авыру буенча бер мөрәҗәгать Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 2020 елга 1 565,2 сум, 2021 елга 1 580,3 сум, ММИ чаралары исәбеннән – 2020 елга 1 362,5 сум, 2021 елга 1 419,2 сум;

мәҗбүри медицина иминияте акчалары исәбеннән амбулатор шартларда кичектергесез формада медицина ярдәмен күрсәткәндә бер тапкыр булу – 2020 елга 616,1 сум, 2021 елга 650,0 сум;

көндезге стационарлар шартларында дәвалауның бер очрагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 2020 елга 18 014,2 сум, 2021 елга 18 188,0 сум, ММИ чаралары исәбеннән – 2020 елга 20 112,9 сум, 2021 елга 21 145,2 сум, «онкология» юнәлеше буенча дәвалауның бер очрагы мәҗбүри медицина

иминияте чаралары исәбеннән – 2020 елга 74 796,0 сум, 2021 елга 77 835,0 сум була;

ММИ чаралары хисабына экстракорпораль аталануның бер очрагы – 2020 елга 118 691,6 сум, 2021 елга 124 219,7 сум;

стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) госпитализациянең бер очрагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 2020 елга 97 115,3 сум, 2021 елга 98 550,7 сум, ММИ чаралары исәбеннән – 2020 елга 34 986,0 сум, 2021 елга 37 512,8 сум, «онкология» юнәлеше буенча госпитализациянең бер очрагы – 2020 елга 99 208,9 сум, 2021 елга 109 891,2 сум;

медицина тернәкләндерүгә буенча махсуслаштырылган хастаханәләрдә һәм «медицина тернәкләндерүе» юнәлеше буенча медицина ярдәме күрсәтүче үзәкләрдә һәм медицина оешмаларының реабилитация бүлекләрендә бер очрак ММИ акчалары исәбеннән – 2020 елга 34 928,1 сум, 2021 елга 35 342,5 сум;

стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) бер көн (паллиатив медицина ярдәме койкаларын һәм шәфкать туташлары карау койкаларын да кертеп) – 2020 елга 2 528,9 сум, 2021 елга 2 568,8 сум

Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә тарифлар ММИ территориаль программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турында тариф килешүе һәм мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмаларын күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы ТММИФ бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәмен түләү тәртибен һәм тарифларны билгеләү турында тариф килешүе белән раслана.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. ММИ Территориаль программасын гамәлгә ашырганда медицина ярдәме өчен түләүнең түбәндәге ысуллары кулланыла:

амбулатор шартларда күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә:

медицина ярдәме күләме берәмлеге өчен түләү белән бергә беркетелгән затларга финанслауның җан башына исәпләнгән нормативы буенча – медицина хезмәте өчен, карау өчен, мөрәҗәгать иткән өчен (тәмамланган очрак);

медицина ярдәме күләме берәмлеге өчен – медицина хезмәте күрсәткән өчен, мөрәҗәгать иткән өчен (тәмамланган очрак) (территориясендә ММИ полисы бирелгән Россия Федерациясе субъектыннан читтә иминләштерелгән затларга күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә кулланыла, шулай ук беркетелгән затлар булмаган аерым медицина оешмаларында кулланыла);

стационар шартларда күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә, шул исәптән махсуслаштырылган медицина оешмаларында (структур бүлекчәләрдә) медицина реабилитациясе өчен:

тиешле авырулар төркеменә кертелгән авыруны дәвалауның тәмамланган очрагы (шул исәптән клиник-статистик авырулар төркемнәре) өчен;

пациентны башка медицина оешмасына күчергәндә медицина ярдәме күрсәтүнең туктатылган очрагы, алга таба дәваланудан пациент язмача баш тартканда пациентны медицина оешмасыннан вакытыннан алда чыгару, үлем белән тәмамланган вакытта, шулай ук диагностика тикшеренүләрен уздырганда, диализ хезмәтләре күрсәткәндә өземтә алуы өчен;

көндезге стационар шартларында күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә:

тиешле авырулар төркеменә кертелгән авыруны дәвалауның тәмамланган очрагы (шул исәптән клиник-статистик авырулар төркемнәре) өчен;

пациентны башка медицина оешмасына күчергәндә медицина ярдәме күрсәтүнең туктатылган очрагы, алга таба дәваланудан пациент язмача баш тартканда пациентны медицина оешмасыннан вакытыннан алда чыгару, үлем белән тәмамланган вакытта, шулай ук диагностика тикшеренүләрен уздырганда, диализ хезмәтләре күрсәткәндә өземтә алуы өчен;

медицина оешмасыннан читтә күрсәтелгән ашыгыч медицина ярдәмен түләгәндә (ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме бригадаларын чакыру урыны буенча), шулай ук медицина эвакуациясе вакытында транспорт чарасында – ашыгыч медицина ярдәмен чакырту өчен түләү белән бергә финанслауның җан башына исәпләнгән нормативы буенча.

Профилактик медицина тикшерүләрен, шул исәптән диспансерлаштыру кысаларында түләү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган медицина тикшеренүләре күләме нигезендә медицина ярдәме күләме берәмлеге (комплекслы карау) өчен гамәлгә ашырыла.

Медицина ярдәмен түләгәндә амбулатор, стационар шартларда һәм көндезге стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчә составында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында әлеге медицина оешмасына беркетелгән затларга, медицина ярдәме өчен түләүне һәм күрсәтелгән медицина оешмасы тарафыннан бирелә торган шартларны исәпкә алып, медицина оешмасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелек күрсәткечләрен (медицина ярдәме күләме күрсәткечләрен дә кертеп) финанслауның җан башына исәпләнгән нормативы буенча түләү ысулы кулланылырга мөмкин.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Программада каралган финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары (федераль бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча) тәшкил итә:

Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән (бер кешегә исәпләгәндә) 2019 елда – 3 571,1 сум, 2020 елда – 3 514,7 сум, 2021 елда – 3 517,9 сум;

мәҗбүри медицина иминияте база программасын финанслауга ММИ акчалары исәбеннән (бер иминләштерелгән затка исәпләгәндә) 2019 елда – 11 678,0 сум, 2020 елда – 12 436,5 сум, 2021 елда – 13 179,2 сум.

2019 елда Программаның бәясе – 58 178 548,9 мең сум, 2020 елда – 60 828 929,4 мең сум, 2021 елда – 63 653 104,7 мең сум (әлеге Программага 3 һәм 4 нче кушымталар), шул исәптән:

2019 елда база программасын гамәлгә ашыруга ММИ акчалары исәбеннән – 44 205 501,2 мең сум, 2020 елда – 47 076 503,6 мең сум, 2021 елда – 49 888 229,5 мең сум;

2019 елда Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – 13 973 047,7 мең сум, 2020 елда – 13 752 425,8 мең сум, 2021 елда – 13 764 875,2 мең сум.»;

Программага 1, 3, 4 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

5 нче кушымтада:

«Медицина ярдәме сыйфаты критерийларының максатчан әһәмияте» таблицасына түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «27. Ел дәвамында тормышта беренче тапкыр теркәлгән авыруларның гомуми санында профилактик медицина тикшерүләрендә беренче тапкыр ачыкланган авырулар өлеше, шул исәптән диспансерлаштыру кысаларында | процент | 12,5 | 14,0 | 15,5 |
| 28. Ел дәвамында эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәк затларның тормышта беренче тапкыр теркәлгән авыруларның гомуми санында профилактик медицина тикшерүләрендә беренче тапкыр ачыкланган авырулар өлеше, шул исәптән диспансерлаштыру кысаларында | процент | 4,6 | 4,6 | 4,6 |
| 29. Ел дәвамында тормышта беренче тапкыр теркәлгән онкология авыруларының гомуми санында профилактик медицина тикшерүләре вакытында беренче тапкыр ачыкланган онкология авырулары өлеше, шул исәптән диспансерлаштыру кысаларындаа | процент | 29,4 | 29,5 | 29,6 |
| 30. Яман шешле пациентларның гомуми санында диспансер күзәтүе астына алынган яман шешле пациентлар өлеше | процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| 31. Паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ булган пациентларның гомуми санында паллиатив медицина ярдәме алган пациентларның өлеше | процент | 70,5 | 70,5 | 70,5 |
| 32. Паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә авыртусызландыруга мохтаҗ пациентларның гомуми санында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү чикләрендә авыртусызландыру алучы пациентлар өлеше | процент | 78,0 | 78,0 | 78,0»; |

«Медицина ярдәменнән файдалану критерийларының максатчан әһәмияте» таблицасына түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «13. Медицина оешмасы регистратурасына турыдан-туры мөрәҗәгать итмичә гражданнар табибка язылу өлеше | процент | 78,1 | 78,1 | 78,1 |
| 14. Яшәү урыны буенча, шул исәптән өйдә дә паллиатив медицина ярдәме алган пациентлар саны | кеше | 6 500 | 6 500 | 6 500 |
| 15. Яшәү урыны буенча теркәлгән Татарстан Республикасы чикләрендә аларның фактта булу урыны буенча паллиатив медицина ярдәме күрсәтелгән пациентлар пациентлар саны | кеше | 50 | 50 | 50»; |

6 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);
Программага 7 нче кушымтаны өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин